ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29 июнь, 2023 ел № 25/6

Шәһәр Советының 2022 елның 26 декабрендәге 19/4 номерлы Карары белән кабул ителгән акцияләрнең йөз проценты (өлеше) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенә караган муниципаль унитар предприятиеләр һәм хуҗалык җәмгыятьләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының, баш бухгалтерларының хезмәт өчен түләү шартлары һәм тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 145 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, «Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» 2002 елның 14 ноябрендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 28 статьясы 52 пункты, Шәһәр Советының «Хезмәткә түләүнең аерым сорауларын җайга салу турында» 2017 елның 22 февралендәге 15/7 номерлы карары нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2022 елның 26 декабрендәге 19/4 номерлы Карары белән кабул ителгән акцияләрнең йөз проценты (өлеше) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенә караган муниципаль унитар предприятиеләр һәм хуҗалык җәмгыятьләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының, баш бухгалтерларының хезмәт өчен түләү шартлары һәм тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Җитәкченең вазыйфаи окладын исәпләү өчен тапкырлау коэффициентын билгеләгәндә, вазыйфаи оклад билгеләнгән айның беренче числосына хезмәткәрләрнең уртача исемлек саны исәпкә алына. Штат расписаниесен үзгәртү кварталга бер тапкыр гына рөхсәт ителә.»;

2) 7 пунктның 1 нче таблицасындагы 3 нче багана исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:«Оешма хезмәткәрләренең уртача исемлек саны»;

3) 7 пунктның 3 пунктчасында 1 нче таблицадагы 4 юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «4. | Автомобиль транспорты эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар | 10 кадәр | 4,81 |
| | | 11 дән 100 кадәр | 5 |
| | | 101 дән 200 кадәр | 5,5 |
| | | 201 дән 300 кадәр | 6 |
| | | 301 дән 400 кадәр | 6,5 |
| | | 401 дән 500 кадәр | 7;»; |

4) 8 пунктның 2 пунктчасының дүртенче абзацында «календарь елның 1 гыйнварына» сүзләрен «айның беренче числосына» сүзләренә алыштырырга;

5)8 пунктның 2 нче таблицасындагы 3 нче багана исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Оешма хезмәткәрләренең уртача исемлек саны»;

6) 11 пунктның 1 пунктчасының икенче абзацында «Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән күләмдә» сүзләрен төшереп калдырырга;

7)11 пунктның 2 пунктчасында «төзелгән хезмәт шартнамәсе шартлары нигезендә кимендә өч календарь көн» сүзләрен «өч календарь көн» сүзләренә алыштырырга.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев